КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 декабрь г.Казань № 1292

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карарына ( Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 502 нче, 2022 ел, 11 март, 217 нче, 2022 ел, 9 август, 780 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. Бу карар 2027 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар өчен приютлар эшчәнлеген оештыру тәртибен һәм хайваннарны тоту нормаларын раслау турында» 2020 ел, 28 февраль, 150 нче карарына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Бу карар 2027 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин